**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 30 ноябре № 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Сугышлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан; балачак инвалидларыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашучылардан; срочная хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2026 елда 1500 (Бер мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башкаларны ремонтлау (Сугышлы авылында Үзәк, Гафиятуллин, Гагарин, Хәлиуллин урамнары буенча урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Сугышлы авылы территориясендә механикалаштырылган һәм кулдан үлән чабу хезмәтләре өчен түләү; "Айлин" кибете артындагы җәяүлеләр күпере районында авария хәлендәге һәм карт агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Сугышлы авылы зиратларында авария хәлендәге иске агачларны һәм куакларны кисү);

4) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сугышлы авылында Үзәк, Гафиятуллин, Гагарин, Насос, Хәлиуллин урамнарындагы юлларны кардан чистарту, Сугышлы авылы Гафиятуллин, Насос, Гагарин, Хәлиуллин урамнарында юллардагы чокырларны ремонтлау)».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы ав., Үзәк ур., 27 йорт буенча административ бинада, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Зыятдинова